КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 29 май г.Казань № 454

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Закон территориясе» еллык республика конкурсын үткәрү турында» 2012 ел, 20 февраль, 135 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Закон территориясе» еллык республика конкурсын үткәрү турында» 2012 ел, 20 февраль, 135 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «предприятиеләр һәм оешмалар, мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренең» сүзләрен «оешмаларның» сүзенә алыштырырга;

5 нче пунктта «Татарстан Республикасында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программаны» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган «Закон территориясе» еллык республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәдә:

1.2 – 1.4 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Конкурста муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыклары һәм башкарма комитетлар җитәкчеләре, авыл җирлекләре башлыклары, теләсә кайсы милек рәвешләрендәге оешмалар җитәкчеләре, белем бирү оешмалары, үсмерләр һәм яшьләр белән эшли торган спорт, мәдәният үзәкләре, клублар җитәкчеләре, шулай ук шәхси саклау оешмалары, хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләре катнаша алырга мөмкин.

1.3. Конкурс үткәрү вакытлары һәм шартлары турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының һәм Хокук бозуларны

профилактикалау буенча Татарстан Республикасы хөкүмәт комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында урнаштырыла.

1.4. Конкурс комиссиясе конкурс йомгаклары турындагы мәгълүмати хәбәрне конкурска йомгаклар ясалган көннән 10 көн эчендә Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының һәм Хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы хөкүмәт комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында бастырып чыгаруны тәэмин итә.»;

2.1 нче пунктта «предприятиеләр һәм оешмаларның, мәгариф учреждениеләренең» сүзләрен «оешмаларның» сүзенә алыштырырга;

3.1 нче пунктта:

«в» пунктчасында «предприятиеләр һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

«г» пунктчасында «югары һәм урта һөнәр белеме бирү учреждениеләре» сүзләрен «белем бирү оешмалары» сүзләренә алыштырырга;

«д» пунктчасында «предприятиеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алыштырырга;

4.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

«Авыл җирлеге территориясендә хокук тәртибен тәэмин итүгә өлеш керткән өчен» (әлеге номинациядә авыл җирлекләре башлыклары бүләкләнә);

«Муниципаль район һәм шәһәр округы территориясендә хокук тәртибен тәэмин итүгә өлеш керткән өчен» (әлеге номинациядә муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары башлыклары һәм (яки) җитәкчеләре бүләкләнә);

«Хокук саклау эшчәнлегенә ярдәм күрсәтүгә өлеш керткән өчен» (әлеге номинациядә оешмалар җитәкчеләре бүләкләнә);

«Мәгариф оешмалары укучылары арасында хокук бозуларны профилактикалауга өлеш керткән өчен» (әлеге номинациядә мәгариф оешмалары җитәкчеләре бүләкләнә);

«Үсеп килүче буынга тәрбия бирүгә, яшьләрдә һәм үсмерләрдә җәмгыятьнең хокукый нигезләренә карата хөрмәт тәрбияләүгә өлеш керткән өчен» (әлеге номинациядә мәгариф оешмалары, үсмерләр һәм яшьләр белән эшли торган спорт, мәдәният үзәкләре, клублар җитәкчеләре һәм (яки) хезмәткәрләре бүләкләнә);

«Шәхси саклау оешмаларын җәлеп итеп, иҗтимагый тәртипне тәэмин итүгә өлеш керткән өчен» (әлеге номинациядә шәхси саклау оешмаларының гамәлгә куючылары һәм (яки) җитәкчеләре бүләкләнә);

«Җәмәгатьчелекне җәлеп итеп, иҗтимагый тәртипне тәэмин итүгә өлеш керткән өчен» (әлеге номинациядә хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый берләшмәләрнең гамәлгә куючылары һәм (яки) әгъзалары бүләкләнә, лицензия таләпләрен күп тапкыр һәм (яки) тупас бозулары ачыкланган шәхси саклау оешмаларына конкурста катнашырга рөхсәт ителми).»;

5.2 нче пунктта:

икенче абзацта «10 февральгә кадәр» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «Мәгариф учреждениеләре укучылары» сүзләрен «Мәгариф оешмалары укучылары» сүзләренә алыштырырга;

җиденче абзацта «предприятиеләрен» сүзен «оешмаларын» сүзенә алыштырырга;

тугызынчы абзацта «30 апрельгә кадәр» сүзләрен төшереп калдырырга;

унынчы абзацта «30 апрельгә кадәр» сүзләрен төшереп калдырырга;

6.3 нче пунктта «истәлекле билгеләр,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 1 – 7 нче кушымталарны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган конкурс комиссиясе составын (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин